**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

19.11.2013 №672-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыкларын үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының түбәндәге норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төзелеш объектын урнаштыру урынын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 23 апрелендәге 149-п номерлы боерыгын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2012 елның 17 июлендә теркәлгән, №1564);

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 23 апрелендәге 149-п номерлы боерыгы белән расланган Төзелеш объектын урнаштыру урынын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 5 февралендәге 61-п номерлы боерыгын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2011 елның 28 мартында теркәлгән, № 1848);

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 7 маендагы 266-п номерлы боерыгының 1 пунктын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 28 маенда теркәлгән, №1879).

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.Г. Сидоров